РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Сармановский муниципальный район
Совет
Рангазарского сельского поселения
423377 с. Рангазар ул. Советская дом 48 Телефон (85559) 4 – 36 – 54

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Сарман муниципаль районы
Рангазар авыл җирлеге
Советы
423377 Рангазар авылы Совет ур. 48 йорты
Телефон (85559) 4 – 36 – 54

РЕШЕНИЕ

КАРАР

24 нче ноябрь 2023 ел

№ 18

«Җир салымы турында» Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге советының 2020 елның 18 мартындагы 2 номерлы карарына үзгәрешләр керту хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр керту турында һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясының 1 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору хакында» 2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 113 пункты, Сарман муниципаль районының «Рангазар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Рангазар авыл җирлеге карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге Советының 2020 елның 18 мартындагы 2 номерлы «Җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1.2.1 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.2.1 торак фонды һәм (яки) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары белән биләнгән җир кишәрлекләренә (торак фондына һәм (яки) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез милек объектына туры килә торган җир кишәрлегенең бер өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата (эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш);

2. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Рангазар авыл җирлеге
Советы рәисе А.Р.Шарипова